# Татар телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең
# 7 нчы сыйныфында укучы татар балалары өчен
# татар теленнән үткәрелә торган район олимпиадасы биремнәре
# (2015/2016 нчы уку елы)

**Үткәрү вакыты- 3 сәгать** **Максималь балл - 50**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Кайсы рәттәге сүзләрнең барысында да [w] авазы әйтелә? ***(2 балл)***
   а) дөбердәү, куаныч, валюта, куалау;
   ә) һәвәскәр, булмау, ваклаучы, гәүдә;
   б) ватандаш, гөжләү, вектор, богау;
   в) димләү, август, уалу, дуамал.

2. Кече тел ассимиляциясе күзәтелгән сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а)кышка;
   ә) унбиш;
   б) борынгы;
   в) болыннар.

3.Бирелгән сүзнең басымы үзгәргән очракта омонимның кайсы төре барлыкка килә?
Атла□с – ... ***(2 балл)***
   а) саф лексик омоним;
   ә) омоформа;
   б) омофон;
   в) омограф.

4. Мәкальдәге төшеп калган сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
*Һавадагы торнага алданып, кулыңдагы ... ычкындырма.*
   а) чыпчыкны;
   ә) былбылны;
   б) карганы;
   в) аккошны.

5. Тамырдаш сүзләрдән генә торган төркемне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) очлы, очрау, очсыз, очлаю;
   ә) көндез, көнкүреш, көнлек, көндәлек;
   б) көләч, көлү, көлсу, көлкеле;
   в) калдык, калу, калай, калган.

6. Мәгънәдәш берәмлекләрдән торган парлы сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***
   а) сату-алу;
   ә) аклы-каралы;
   б) эңгер-меңгер;
   в) исәпсез-чутсыз.

7. ***Ярларына*** *ак каеннар үскән* (Р.Әхмәтҗанов) җөмләсендәге билгеләнгән сүзгә морфологик-синтаксик анализ дөрес ясалган вариантны билгеләгез. ***(2 балл)***

а) исем, уртаклык исем, күплек санда, 3 нче зат тартым белән төрләнгән, төшем килешендә, ачыклаган сүзе – *үскән* фигыле, җөмләдә урын хәле, тамыр исем;

ә) исем, уртаклык исем, күплек санда, 3 нче зат тартым белән төрләнгән, юнәлеш килешендә, ачыклаган сүзе – *үскән* фигыле, җөмләдә урын хәле, ясалма исем;

б) исем, уртаклык исем, күплек санда, 3 нче зат тартым белән төрләнгән, юнәлеш килешендә, ачыклаган сүзе – *үскән* фигыле, җөмләдә урын хәле, тамыр исем;

в) исем, уртаклык исем, күплек санда, 3 нче зат тартым белән төрләнгән, төшем килешендә, ачыклаган сүзе – *үскән* фигыле, җөмләдә тәмамлык, ясалма исем.

8. Тиңдәш кисәкләр арасында өтер куелмый торган очракны билгеләгез. ***(2 балл)***

а) каршы куючы теркәгечләр алдыннан;

ә)җыючы һәм бүлүче теркәгечләр ялгызы гына килгәндә;

б) тезү интонациясе булганда;

в) җыючы һәм бүлүче теркәгечләр кабатланып килгәндә.

9. Урын мөнәсәбәтен белдергән сүзтезмәне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) абыйга язу;

ә) чишмә янында йөрү;

б) хикәя турында сөйләшү;

в) җете кызыл яулык.

10. Ачыклаулы мөнәсәбәтне белдерми торган бәйләүче чараны билгеләгез. ***(2 балл)***

а) килеш кушымчалары;

ә) бәйлек һәм бәйлек сүзләр;

б) зат-сан кушымчалары;

в) фигыль формалары.

11. *Хәсәнбай ничектер үзгәргән, бу инде ул **яшәгән**, ул сагынган авыл түгелдер кебек иде* җөмләсендәге ***яшәгән*** сүзе кайсы сүз төркеменә карый? ***(2 балл)***

а) үткән заман хикәя фигыль;

ә) сыйфат;

б) хәзерге заман хикәя фигыль;

в) үткән заман сыйфат фигыль.

12.*Көндезләрен басу эшендә йөрде, тимерчегә булышкалады* (Г. Бәширов) җөмләсендә исем сүз төркеменә кермәгән сүзне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) көндезләрен;

ә) басу;

б) эшендә;

в) тимерчегә.

13. *Болында безне кошлар сайрап каршы алдылар* (Г. Ибраһимов) җөмләсендәге сүзтезмә булмаган сүзләр тезмәләрен билгеләгез. ***(4 балл)***

а) болында каршы алдылар;

ә) безне каршы алдылар;

б) кошлар каршы алдылар;

в) сайрап каршы алдылар;

г) каршы алдылар;

14. Бәйләнешле текст барлыкка килсен өчен, җөмләләрне нинди тәртиптә куярга кирәк? ***(2 балл)***

1) *Ленар сәхнә уртасына Татарстан флагын күтәреп чыкты*.

2) *Ленар, микрофон алдына килеп, рәхмәт әйтә башлады.*

3) *Ничек дип игълан иттеләр әле?*

4) *Кул чабарга керештеләр.*

5) “*Татарстаннан Ленар Самат улы Вәлиев, Иоганн Себастьян Бах сонаталарын башкарып, беренче урынны алды”, - диделәр.*

6) *Бу юлы зал Татарстанны, аның яшелле-аклы-кызыллы төсләрен алкышлады.* (Г. Гыйльмановтан)

а) 3,5,1,4,6,2;

ә) 2,5,4,6,1,3 ;

б) 4,3,5,4,1,2;

в) 1,5,3,4,6,2.

15. ***Соң*** сүзе бәйлек булып килгән җөмләне билгеләгез. ***(2 балл)***

а) Быел көз соң килде.

ә) Әхсән уйга калды. Аннан соң укытучыга карады. (Н. Акмал);

б) – Нәрсә өйрәтермен соң мин сиңа? (Н. Акмал);

в) Соң, күптән шулай диләр аны!

## II Теоретик бирем.

Җаваплар языгыз. ***(8 балл)***

1) Җөмләдә сүзләр үзара ... төрле юл белән бәйләнә: ...

2) Тезүле бәйләнешне белдерүче чаралар: ...

3) Ияртүле бәйләнештә торган сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләр: ...

4) Татар телендәге сүзтезмәләрнең исемнәре: ...

## III Иҗади бирем.

*Хәйран булып җырны тыңлап тордым,*
*Ташлап түбән дөнья уйларын ,*
*Күз алдымда күргән төсле булдым*
*Болгар һәм Агыйдел буйларын.*

Г. Тукайның “Милли моңнар” шигыреннән алынган бу өзек нинди фикерләр уята?

Тукай сүзләре, татар җыры, татар моңы Сезгә ничек тәэсир итә? Шул хактагы фикерләрегезне 12-13 җөмләдән торган текст итеп языгыз. ***(10 балл)***